«АТНА ВАКЫЙГАЛАРЫ»
№ 43 (350) | **30 октябрь - 5 ноябрь** 2020 ел

Республика яңалыклары –
**www.tatar-inform.tatar** сайтында

Кулланучы хәбәрләре

# Кулланучы хәбәрләре

**«Күптән түгел кибеттә ташлама белән кышкы аяк киеме сатып алдым. Салкыннарга да озак калмады бит, шуңа кулай бәядән генә ботинка алырга уйладым. Әмма аның сыйфаты өчен җавап бирә алмыйм. Сыйфатсыз булуы киеп йөри башлаганнан соң гына ачыкланса, нишләргә? Шикаять белән кибеткә мөрәҗәгать итәргә хакым бармы?»**

**Сергей П.**

«Кулланучыларның хокукларын яклау турында»гы РФ законының 19 маддәсе 2 пункты 1 абзацы нигезендә, товарның гарантия вакыты, шулай ук куллану срогы (әгәр килешүдә башкалар каралмаган булса) кулланучы товарны сатып алган көннән башлана. Әгәр кайчан сатып алуыгызны хәтерләмәсәгез, срок товар эшләп чыгарылган көннән башлап санала.

Сезонлы товарлар өчен (өс, аяк киеме һәм башкалар) бу срок тиешле сезон башлангач исәпләнә. Бу Законның 19 маддәсе 2 пунктындагы 2 абзацында һәм РФ Хөкүмәтенең 1998 елның 19 гыйнварында дөнья күргән 55нче карары белән расланган Товарларның аерым төрләрен сату кагыйдәләренең 30 пунктында билгеләнгән. Кышкы ботинка – сезонлы товар. Әгәр кышкы сезон башлану көненнән исәпләнгән гарантия срогы чыкканчы, сыйфатсыз товар сатуга дәгъва белдереп кибеткә мөрәҗәгать итсәгез, сатучы сезнең таләпләрне канәгатьләндерергә тиеш.

Гомуми кагыйдә буенча (законның 13 маддәсе 4 пункты, 14 маддәсе 5 пункты, 28 маддәсе 6 пункты) йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат итүне исбатлау сатучыга (җитештерүче, башкаручы, вәкаләтле оешма яки шәхси эшмәкәр, импортер) йөкләнә.

**Шул рәвешле, сез сатучыдан кышкы ботинканы шундый ук товарга алыштыруны таләп итәргә, алар өчен түләнгән акчаны кире кайтарырга яки сатучы хисабына ремонт таләп итәргә хокуклы.**



# Тун җөйләреннән таралып китсә...



**«Җәй башында чәшке тун сатып алдым. Тунга гарантия вакыты нибары 30 көн иде. Хәзер кышка әзерләнгәндә, тунны карадым һәм берничә җиреннән җөе сүтелгәнен күрдем. Сатучыга шикаять белдерә аламмы?**

**Елена Р.»**

Сезонлы товарлар өчен (өс, аяк киеме һәм башкалар) бу срок тиешле сезон башлангач исәпләнә. Бу Законның 19 маддәсе 2 пунктының 2 абзацында һәм РФ Хөкүмәтенең 1998 елның 19 гыйнварында дөнья күргән 55нче карары белән расланган Товарларның аерым төрләрен сату кагыйдәләренең 30 пунктында билгеләнгән.

Тун – мех өс киеме санала, шуңа күрә сезонлы товарларга карый. Товар сатып алу урыны буенча Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органының норматив акты нигезендә, кулланучыга сезоннарның озынлыгына бәйле срокларын билгеләргә кирәк. Әгәр дә кулланучының сыйфатсыз товар сатуына бәйле таләпләре, кышкы сезон башлану датасыннан исәпләнә торган гарантия срогы вакытында күрсәтелсә, алар сатучы тарафыннан канәгатьләндерелергә тиеш.

**Шул рәвешле, әгәр тун кышкы сезон башлангач 30 көн дәвамында сүтелгән булса, кулланучы аны алмаштыруны, акчаларны кире кайтаруны һәм ремонт ясатуны таләп итә ала. Моннан тыш, Законның 10 маддәсенең 5 пункты нигезендә, әгәр гарантия срогы ике елдан кимрәк булса һәм бу вакыт узгач кулланучы товарда кимчелекләр таба икән, сатып алучы ике ел дәвамында сатучыга (җитештерүчегә) Законның 18 маддәсендә каралган таләпләрне белдерергә хокуклы. Моны ул товардагы җитешсезлекләр кулланучыга тапшырылганчы яисә аңа кадәр булган сәбәпләр аркасында барлыкка килгәнен исбат итсә генә эшли ала**